**СОВЕТ ХОЗЕСАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХУҖА ХӘСӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

27.04.2020 Хуҗа Хәсән ав. № 8

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы
Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Советының кайбер
карарларын юкка чыгару турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы, «Азык-төлек продуктларының сыйфаты һәм куркынычсызлыгы турында» һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 37 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 1 мартындагы 47-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм муниципаль хокукый актларны муниципаль хезмәт турындагы гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авылы җирлеге Советының:

- Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авылы җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 2017 елның 7 августындагы 17 номерлы;

- «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авылы җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрне бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 06 апрелендәге 4 номерлы.

-«Азык-төлек продуктларын сату һәм аларның әйләнешен гамәлгә ашыруга таләпләр һәм Хуҗа Хәсән авыл җирлеге территориясендә базар, сәүдә

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга һәм

Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Хуҗа Хәсән авыл җирлеге
Башлыгы Матвеева С.П.